**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТЕЛӘНЧЕ ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«15» ноябрь, 2024ел Теләнче Тамак авылы № 23

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Теләнче Тамак авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Теләнче Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында «нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 31 октябрендәге 8/1 номерлы Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Советы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2024 елның 28 ноябренә 18:00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Теләнче Тамак авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2025 елда яшәү урыны буенча Теләнче Тамак авыл җирлеге Теләнче Тамак авылы территориясендә теркәлгән һәр бәлигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

«- торак пункт территориясен төзекләндерү (Теләнче-Тамак авылы Татарстан урамы буенча гомуми файдаланудагы территорияне төзекләндерү; мәдәният йорты территориясендә балалар мәйданчыгын төзекләндерү балалар уен элементларын сатып алу, урнаштыру, Сабантуй үткәрү урынын төзекләндерү агачларны кисү, стоянкаларны төзекләндерү)
- урамнарны яктырту эшләрен башкару (Теләнче-Тамак торак пунктында урамнарны яктыртуны ремонтлау өчен электр җиһазлары һәм комплектлау элементлары (яктырткычлар) сатып алу)
- торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( Теләнче Тамак авылы Красноармейская урымнда юл ремонты) ».

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай районы, Теләнче Тамак авылы, Татрстан урамы, 19 йорт.

4. РФ Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү, контракт буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, Теләнче Тамак авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә.

5. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

8. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Теләнче Тамак авыл җирлеге Башлыгы Р.Ш. Нәҗметдинов